КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 ел, 09 октябрь г.Казань № 812

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында» 2018 ел, 31 май, 409 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Кино- һәм видеофильмнарны прокатка бирү һәм күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтү сыйфаты стандартларын раслау турында» 2018 ел, 31 май, 409 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 04 декабрь, 1082 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган кинофильмнар күрсәтү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфаты стандартында:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезе

2.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Граждан кодексы;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Советлар Союзы Геройлары, Россия Федерациясе Геройлары һәм Дан орденының тулы кавалерлары статусы турында» 1993 елның 15 гыйнварындагы 4301-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә кинематографиягә дәүләт ярдәме турында» 1996 елның 22 августындагы 126-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кинозалларда фильмнар күрсәтү һәм мондый хезмәтләр күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1994 елның 17 ноябрендәге 1264 номерлы карарының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 16 августындагы 1338 номерлы карары;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары” бүлеге, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген раслау турында» 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Кино- һәм видеохезмәт күрсәтү вакытында фильм күрсәтү алдыннан балалар арасында аның таралуын чикләү турында мәгълүмати продукция билгесен һәм (яисә) текст кисәтүен урнаштыру тәртибен раслау турында» 2012 елның 16 августындагы 893 номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Гамәлгә куючысы Россия Федерациясе Хөкүмәте йөзендә Россия Федерациясе булган, эшчәнлегенең төп максатлары илебез кинематографиясенә ярдәм итү, аның конкурентлык сәләтен арттыру, милли мәнфәгатьләргә туры килә торган сыйфатлы фильмнар булдыру өчен шартлар тәэмин итү һәм 2013 елда Россия Федерациясендә милли кинофильмнарны популярлаштыру булган коммерциягә карамаган оешманы сайлап алу тәртибе турында» 2013 елның 8 февралендәге 113 номерлы боерыгы;

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең «Автор һәм (яисә) чиктәш хокуклар объектларын (фотография әсәрләреннән һәм фотографияләргә охшаш ысуллар белән алынган әсәрләрдән тыш) таратучы мәгълүмат ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген чикләү чараларын күрү турында хокук иясенең гаризасы формасын яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып аларны алу өчен кирәкле

мәгълүматны, хокук иясе рөхсәтеннән яисә башка законлы нигездән тыш, раслау турында» 2015 елның 29 апрелендәге 42 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

Татарстан Республикасы Гаилә кодексы;

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре төрләре кисемтәсендә дәүләт хезмәтләре һәм башкарыла торган һәм башкарыла торган эшләр исемлегенең Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнми.»;

3 бүлек таблицасының 1 пунктындагы 2 графасына «алу» сүзеннән соң «дәүләт» сүзен өстәргә;

4.5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кинозалларда фильмнар күрсәтү һәм мондый хезмәтләр күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1994 елның 17 ноябрендәге 1264 номерлы карарының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 16 августындагы 1338 номерлы карары белән расланган Кинозалларда фильмнар күрсәтү һәм мондый хезмәтләр күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре нигезендә фильмнарны һәм башка аудиовизуаль әсәрләрне гавами күрсәтү.»;

4.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.7. Дәүләт хезмәтен алучылар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кинозалларда фильмнар күрсәтү һәм мондый хезмәтләр күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1994 елның 17 ноябрендәге 1264 номерлы карарының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 16 августындагы 1338 номерлы карары белән расланган Кинозалларда фильмнар күрсәтү һәм мондый хезмәтләр күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен үтәргә тиеш.»;

6.1 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим

кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;

7.5 пунктның сигезенче абзацында «күрсәтүче» сүзеннән соң «дәүләт» сүзен өстәргә;

8.2 пунктта «халыкка» сүзен «дәүләт хезмәтен алучыларга» сүзләренә алмаштырырга;

8.5 пунктта:

татар текстында беренче абзацка «Хезмәткәре» сүзе алдына «Оешма» сүзен өстәргә;

татар текстында икенче абзацка «күрсәтү» сүзе алдына «дәүләт» сүзенә өстәргә;

11 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы»;

12.2 пунктта:

татар текстында «юнәлтелгән» сүзе алдыннан «дәүләт хезмәтен алучы тарафыннан» сүзләрен өстәргә;

«мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

12.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.4. Шикаять Оешмага, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кергәннән соң өч эш көне эчендә теркәлергә тиеш, һәм аның теркәлгән көненнән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, әгәр дә Оешманың, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының дәүләт хезмәте алучыдан документлар кабул итүдән баш тартуга яки җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүгә яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять бирелгән очракта – теркәлгән көненнән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш.»;

12.5 пунктта тиешле килешләрдә «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен тиешле килешләрдә «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.6 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәте алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.7 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.9 пунктта «Мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «Дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында 13 бүлекнең исеменә «дәүләт хезмәте» сүзләре алдыннан «дәүләт хакимияте органнары ягыннан» сүзләрен өстәргә;

14 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Дәүләт хезмәтен түләүле яки бушлай күрсәтү турында мәгълүмат

14.1. Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

14.2. Дәүләт хезмәте сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, милләтара һәм диннәр арасындагы түземлелек, тәмәке тартуга, наркоманиягә, терроризмга һәм

башка тискәре социаль күренешләргә каршы көрәш буенча дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында, шулай ук кинофестивальләр, акцияләр һәм әлеге тематикадагы башка чаралар вакытында фильмнар һәм башка аудиовизуаль әсәрләр күрсәтүне тормышка ашырганда бушлай күрсәтелә.

14.3. Дәүләт хезмәте бәяләрен Оешма мөстәкыйль рәвештә билгели.

14.4. Оешма тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр тарифлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) өчен гражданнар һәм юридик затлар түләвен билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1170 нче карарына туры китереп билгеләнә.

14.5. Әлеге Стандартның 1.2 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәте алучыларга, дәүләт хезмәте теләсә кайсы сеанска билет бәясеннән 50 процент ташлама белән бирелә, әгәр дә алар дәүләт хезмәтен ташламалы шартларда алу хокукын раслаучы билгеләнгән үрнәктәге документны күрсәтсәләр.

14.6. Билетлар сату Оешманың кассаларында, Оешманың интернет-кассалары аша һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Оешма билетларны сату буенча агентлык килешүе төзегән сайтлар аша башкарыла.

әлеге карар белән расланган кино- һәм видеофильмнарны прокатлау буенча дәүләт хезмәте сыйфаты стандартында:

2 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Дәүләт хезмәтен күрсәтүнең хокукый нигезе

2.1. Дәүләт хезмәте түбәндәге закон чыгару һәм башка норматив хокукый актлар нигезендә күрсәтелә:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Граждан кодексы;

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы;

«Кулланучылар хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Мәдәният турында Россия Федерациясе законнары нигезләре» 1992 елның 9 октябрендәге 3612-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;

«Янгын куркынычсызлыгы турында» 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясендә кинематографиягә дәүләт ярдәме турында» 1996 елның 22 августындагы 126-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон;

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы Федераль закон;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кинозалларда фильмнар күрсәтү һәм мондый хезмәтләр күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1994 елның 17 ноябрендәге 1264 номерлы карарының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 16 августындагы 1338 номерлы карары;

Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгының «Мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының квалификация характеристикалары" бүлеге, җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр вазыйфаларының бердәм квалификация белешмәлеген раслау турында» 2011 елның 30 мартындагы 251н номерлы боерыгы;

Россия Федерациясе Мәдәният министрлыгының «Кино- һәм видеохезмәт күрсәтү вакытында фильм күрсәтү алдыннан балалар арасында аның таралуын чикләү турында мәгълүмати продукция билгесен һәм (яисә) текст кисәтүен урнаштыру тәртибен раслау турында» 2012 елның 16 августындагы 893 номерлы боерыгы;

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең «Автор һәм (яисә) чиктәш хокуклар объектларын (фотография әсәрләреннән һәм фотографияләргә охшаш ысуллар белән алынган әсәрләрдән тыш) таратучы мәгълүмат ресурсларыннан файдалану мөмкинлеген чикләү чараларын күрү турында хокук иясенең гаризасы формасын яисә мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләреннән файдаланып аларны алу өчен кирәкле мәгълүматны, хокук иясе рөхсәтеннән яисә башка законлы нигездән тыш, раслау турында» 2015 елның 29 апрелендәге 42 номерлы боерыгы;

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Мәдәният турында» 1998 елның 3 июлендәге 1705 номерлы Татарстан Республикасы Законы;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының стандартлары турында» 2009 ел, 30 июнь, 445 нче карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре күрсәтә торган дәүләт хезмәтләре фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән стандартларына туры килүен бәяләүне уздыру тәртибе турында» 2009 ел, 30 июнь, 446 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының аерым дәүләт учреждениеләре һәм аерым дәүләт учреждениеләре төрләре кисемтәсендә дәүләт хезмәтләре һәм башкарыла торган һәм башкарыла торган эшләр исемлегенең Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана торган якынча исемлеген раслау турында» 2015 ел, 29 сентябрь, 726 нчы карары.

2.2. Дәүләт хезмәтен күрсәтү «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон белән көйләнми.»;

4.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.6. Дәүләт хезмәтен алучылар Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кинозалларда фильмнар күрсәтү һәм мондый хезмәтләр күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе

Хөкүмәтенең 1994 елның 17 ноябрендәге 1264 номерлы карарының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларының аерым нигезләмәләре үз көчләрен югалтуын тану турында» 2021 елның 16 августындагы 1338 номерлы карары белән расланган Кинозалларда фильмнар күрсәтү һәм мондый хезмәтләр күрсәтү белән бәйле хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен үтәргә тиеш.»;

татар текстында 5.1 пунктка «күрсәтелә» сүзе алдына «дәүләт» сүзен өстәргә;

6.1 пунктның икенче абзацында «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгынга каршы режим турында» 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары» сүзләрен «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 16 сентябрендәге 1479 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә янгынга каршы режим кагыйдәләре» сүзләренә алмаштырырга;consultantplus://offline/ref=1390EBD7FFCF1CF370C824CB4B92F9D8DC06008F6B090034A6B1DA6B75C57939A7E7D7C7CEF4273F56BF7558B7A165BD42D9B0A7043B6D53h1n4G

татар текстында 8.5 пунктның беренче абзацына «Хезмәткәре» сүзе алдына «Оешма» сүзен өстәргә;

9.6 пункт таблицасының 10 пунктындагы 2 графасында «кулланучылар» сүзен «алучылар» сүзенә алмаштырырга;

11 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе тасвирламасы»;

12 бүлектә:

12.2 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

12.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12.4. Шикаять Оешмага, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына кергәннән соң өч эш көне эчендә теркәлергә тиеш, һәм аның теркәлгән көненнән алып 15 эш көне эчендә каралырга тиеш, әгәр дә Оешманың, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының дәүләт хезмәте алучыдан документлар кабул итүдән баш тартуга яки җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүгә яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән вакытын бозуга шикаять бирелгән очракта – теркәлгән көненнән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш.»;

12.5 пунктта тиешле килешләрдә «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен тиешле килешләрдә «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.6 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәте алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.7 пунктта «мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

12.9 пунктта «Мөрәҗәгать итүче» сүзләрен «Дәүләт хезмәтен алучы» сүзләренә алмаштырырга;

татар текстында 13 бүлекнең исеменә «дәүләт хезмәте» сүзләре алдыннан «дәүләт хакимияте органнары ягыннан» сүзләрен өстәргә;

14 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Дәүләт хезмәтен түләүле яки бушлай күрсәтү турында мәгълүмат

14.1. Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

14.2. Дәүләт хезмәте сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау, милләтара һәм диннәр арасындагы түземлелек, тәмәке тартуга, наркоманиягә, терроризмга һәм башка тискәре социаль күренешләргә каршы көрәш буенча дәүләт программаларын гамәлгә ашыру кысаларында, шулай ук кинофестивальләр, акцияләр һәм әлеге тематикадагы башка чаралар вакытында фильмнарны прокатка бирүне тормышка ашырганда бушлай күрсәтелә.

14.3. Дәүләт хезмәте бәяләрен Оешма мөстәкыйль рәвештә билгели.

14.4. Оешма тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр тарифлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимияте органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәтү (эшләр башкару) өчен гражданнар һәм юридик затлар түләвен билгеләүнең якынча тәртибен раслау турында» 2010 ел, 30 декабрь, 1170 нче карарына туры китереп билгеләнә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин